КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 8 сентябрь г.Казань № 843

2021 елга Татарстан Республикасында телләрнең күптөрлелеген саклауга булышлык күрсәтүгә юнәлдерелгән проектларны һәм чараларны тормышка ашыруга Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантлары һәм аларны бирү тәртибе турында

Татарстан Республикасында милли (туган) телләрне саклау һәм үстерү максатларында, 2021 елны Татарстан Республикасында Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы дип игълан итүгә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2021 елга «Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы кысаларында Татарстан Республикасында телләрнең күптөрлелеген саклауга булышлык күрсәтүгә юнәлдерелгән проектларны һәм чараларны тормышка ашыруда муниципаль мәдәният учреждениеләренә ярдәм күрсәтү» грантын гамәлгә куярга.

2. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

2021 елга «Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы кысаларында Татарстан Республикасында телләрнең күптөрлелеген саклауга булышлык күрсәтүгә юнәлдерелгән проектларны һәм чараларны тормышка ашыруда муниципаль мәдәният учреждениеләренә ярдәм күрсәтү» гранты һәм аны бирү тәртибе турындагы нигезләмәне;

2021 елга «Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы кысаларында Татарстан Республикасында телләрнең күптөрлелеген саклауга булышлык күрсәтүгә юнәлдерелгән проектларны тормышка ашыруда муниципаль мәдәният учреждениеләренә ярдәм күрсәтү» грантын түләү өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләрен.

3. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына бу карар белән расланган 2021 елга «Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы кысаларында Татарстан Республикасында телләрнең күптөрлелеген саклауга булышлык күрсәтүгә юнәлдерелгән проектларны һәм чараларны тормышка ашыруда муниципаль мәдәният учреждениеләренә ярдәм күрсәтү» гранты һәм аны бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә таянып эш итүне тәкъдим итәргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин